МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

(84342) 5-43-60 ... 5-43-70 ...

№1056 26.12.2018

Постановление Карар

Татарстан Республикасы Чистай
муниципаль районы башкарма
комитетының торак коммуналь
хуҗалык, төзелеш, транспорт, энергетика,
элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге тарафыннан
муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә
ашыру буенча функцияләрне үтәүнең
административ регламентын раслау турында

2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары турында”гы 131 нче Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендә кабул ителгән “ Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне тормышка ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында”гы 294 нче номерлы Федераль закон, 2015 елның 3 ноябрендә кабул ителгән“ Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне тормышка ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында”гы Федераль законына үзгәрешләр кертү турында”гы 306 нчы ФЗның 2нче маддәсенең 2 нче пункты, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 45 нче номерлы законы нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының торак коммуналь хуҗалык, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге тарафыннан муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча функцияләрне үтәүнең административ регламентын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 06.07. 2018 елгы “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы торак коммуналь

хуҗалык, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге тарафыннан муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча функцияләрне үтәүнең административ регламентын раслау турында”гы 534 нче карары көчен югалткан дип табарга.

3. ТР Чистай муниципаль районы башкарма комитетының икътисад бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый-мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol. tatarstan. ru. ) урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Чистай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча беренче урынбасары Л.Х. Кәшәповага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе — Э.Р. Хәсәнов

ТР Чистай муниципаль
районы башкарма комитеты
карары белән расланган

___________ №________

**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының торак коммуналь хуҗалык, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге тарафыннан муниципаль торак фондтан файдаланган һәм саклаган өчен, әлеге фондтагы торак биналарның билгеләнгән санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законның башка таләпләренә туры килүенә, җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының саклanышы тәэмин ителүгә, күпфатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектлары төзелешендә өлешләп катнашу өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек итүгә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча функцияләрне үтәүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Чистай муниципаль районы башкарма комитетының торак коммуналь хуҗалык, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге тарафыннан муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча функцияләрне үтәүнең административ регламенты (алга таба –Регламент) юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең Чистай муниципалҗ районы территориясендә муниципаль торак фондтан файдалану һәм саклау өлкәсендә, әлеге фондтагы торак биналарның билгеләнгән санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законның башка таләпләренә туры килүенә, җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының сакланышы тәэмин ителүгә, күпфатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектлары төзелешендә өлешләп катнашу өлкәсендә контрольлек һәм күзәтчелек итүгә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләрен үтәүләренә контроль буенча чаралар үткәргәндә Чистай муниципаль районы торак коммуналь хуҗалык, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге ( алга таба - муниципаль контроль органы) гамәлләренең срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

1.2 Муниципаль контрольне һәм башка контрольлек итү чараларын оештырганда фнукцияләр түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе белән;

-2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары турында”гы 131 нче Федераль закон белән;

-2008 елның 26 декабрендә кабул ителгән “ Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне тормышка ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында”гы 294 нче номерлы Федераль закон белән;

-Татарстан Республикасының административ хокук бозулар турындагы Кодексы белән;
- Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы белән;
- Чистай муниципаль районы Советының 03.11.2010 елда кабул иткән “Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”гы 2/2 нче карары белән;
РФ Торак кодексы белән, 2004 елның 29 декабре 188 нче Федераль закон;
-2007 елның 8 ноябрендә кабул ителгән “ Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турындагы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 257нче Федераль законы белән;
-РФ Хөкүмәтенең 18.04. 2016 елгы “ Дәүләт контроле (күзәтчелек) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан тикшерүләрне оештырганда һәм үткәргәндә башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә әлеге документлар һәм мәгълүматлар алар карамагында булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары ведомствосында булган оешмаларга ведомствоара мәгълүмати үзараэлемтә кысаларында сорау җибәрү һәм бушлай нигездә, шул исәптән электрон формада документлар һәм (яки) мәгълүмат алу турында”гы 323 карары белән (“ Дәүләт контроле (күзәтчелек) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан тикшерүләрне оештырганда һәм үткәргәндә башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә әлеге документлар һәм мәгълүматлар алар карамагында булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары ведомствосында булган оешмаларга ведомствоара мәгълүмати үзараэлемтә кысаларында сорау җибәрү һәм бушлай нигездә, шул исәптән электрон формада документлар һәм (яки) мәгълүмат алу Кагыйдәләре” белән);
-РФ Хөкүмәтенең 19.04.2016 елгы “Дәүләт контроле (күзәтчелек) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан тикшерүләрне оештырганда һәм үткәргәндә башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә әлеге документлар һәм мәгълүматлар алар карамагында булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары ведомствосында булган оешмаларга ведомствоара мәгълүмати үзараэлемтә кысаларында соратылган һәм алынган документлар һәм ( яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында”гы 724 нче (19.08.2017 елгы редакциядә) Боерыгы белән;
-Татарстан Республикасының 2007 елның 27 декабрендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарын күпфатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектлары төзелешендә өлешләп катнашу өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелекне гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында”гы 66нчы Законы белән;

-әлеге Регламент белән.

1.3. Юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең муниципаль хокукый актларын үтәвенә контроль функцияләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләре булган вазифаи затлар булып торалар:

- муниципаль контроль органы җитәкчесе;
- муниципаль контроль органы җитәкчесе урынбасары.
1.4. Контроль предметы булып гамәлдәге закон тарафыннан билгеләнгән вәкаләтләрне тормышка ашыру кысаларында тәкъдим ителгән мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар тарафыннан билгеләнгән таләпләр җыелмасын үтәү тора.
1.5. Контроль буенча чараларны үткәрү урыны:
- муниципаль контроль органының урнашкан урыны – документлар буенча тикшергәндә;
-юридик затның урнашкан урыны, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеген башкару урыны һәм (яки) аларның эшчәнлекләрен фактта гамәлгә ашыру урыны – күчмә тикшерү вакытында.
1.6. Муниципаль контроль органы җитәкчесе, аның урынбасары юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлекләрен башкарганда муниципаль хокукый актлар таләпләрен әлеге Регламентның1.2. нче пункты нигезендә үтәүләренә тикшерү уздыралар һәм аларның нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләргә карата Россия Федерациясе законында каралган чараларны күрәләр:
-юридик затлар;
-вазифаи затлар;
-шәхси эшмәкәрләр.
1.7.Әлеге Регламентның 1.6.нчы пунктында күрсәтелгән затларга карата контроль буенча чараларны оештыру һәм үткәрү законлылык принциплары нигезендә һәм аларның намуслылык дәрәҗәсендә гамәлгә ашырыла.
1.8. Юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең муниципаль хокукый актлар таләпләрен үтәүләренә контроль функциясен үтәүнең соңгы нәтиҗәсе булып аларны фактта үтәү тора.
1.9. Юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең муниципаль хокукый актлар таләпләрен үтәүләренә контроль функциясен фактта үтәүнең соңгы нәтиҗәсе булып торалар:
-тикшерү нәтиҗәләре буенча акт төзү һәм тапшыру;
- муниципаль хокукый актлар таләпләрен бозуны бетерү турында күрсәтмә тапшыру;
-Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар кодексы белән билгеләнгән тәртиптә эшчәнлекләрен вакытлыча тыю турында беркетмә төзү;
-юридик затның, шәхси эшмәкәрнең мөрәҗәгатен карау нәтиҗәләре буенча җавап әзерләү һәм җибәрү;
- кирәк булганда Россия Федерациясе законы нигезендә чара күрү өчен эчке эшләр, прокуратура, эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектларын дәүләт теркәве органнарына һәм башка күзәтчелек органнарына мәгълүмат әзерләү һәм җибәрү.
1.10. Контроль функциясен үтәү бушлай нигездә гамәлгә ашырыла.

1.11. Муниципаль контроль органы муниципаль контрольне оештырганда һәм гамәлгә ашырганда юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлеген яки гамәлләрен (гамәл кылмауларын), җитештерә һәм сата торган товарлары

(башкарган эшләре, күрсәткән хезмәтләре) мәҗбүри таләпләргә һәм муниципаль хокукый актлар тарафыннан билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләү өчен контроль буенча чаралар үткәрүгә һәм күрсәтелгән таләпләрне үтәүгә анализ ясау, шулай ук тиешле эшчәнлек өлкәсендә муниципаль контрольнең нәтиҗәлелеге мониторингы үткәрү буенча чаралар, тикшерү нәтиҗәләрен исәпкә алу һәм тиешле отчетны төзү өчен экспертларны, эксперт оешмаларын җәлеп итә.

1.11.1 Муниципаль контроль органы тикшерүләр оештырганда һәм уздырганда Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән, башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары ведомствосындагы оешмалардан (әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат алар карамагында булса) ведомствоара мәгълүмати үзараэлемтә кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән срокларда һәм тәртиптә документлар һәм (яки) мәгълүмат сорый һәм бушлай нигездә, шул исәптән электрон формада ала ала.

Белгеч тарафыннан ведомствоара мәгълүмати үзараэлемтә кысаларында башка власть органнарыннан соратып ала торган документлар исемлеге:

- юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;
- күчемсез милек объектлары турында Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;
-территориянең кадастр планы.

Контроль-күзәтү чаралары уздырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тәкъдим итә торган документлар исемлеге:

- вазифаи затның паспорт күчермәсе;
- вазифаи затны билгеләү турында боерыклар;
- күчемсез милек объектларына хокукны билгеләүче документлар.

1.11.2.Салым яки закон тарафыннан саклана торган башка сер тупланган документларны һәм (яки) мәгълүматны сорату, ул ведомствоара мәгълүмати үзараэлемтә кысаларында юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең мәҗбүри таләпләрне үтәү фактын билгеләү зарурлыгын таләп итүче тиешле белешмәне тикшерү шартлары булганда рөхсәт ителә һәм әлеге белешмәләрне тәкъдим итү Федераль закон тарафыннан каралган.

1.11.3. Ведомствоара мәгълүмати үзараэлемтә кысаларында документларны һәм (яки) мәгълүматны тапшыру, аларны ачу, шул исәптән закон тарафыннан каралган очракларда алар белән танышу Россия Федерациясенең дәүләт турындагы закон таләпләрен һәм закон тарафыннан саклана торган башка серен исәпкә алып.

1.12.1. Юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең мәҗбүри таләпләрне бозуларын кисәтү, мәҗбүри таләпләрне бозуга китергән сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерү максатында, муниципаль контроль органы ел саен алар тарафыннан расланa торган бозуларны кисәтүче программалар нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү буенча чаралар үткәрә.

Мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү максатында муниципаль контроль органы:

1) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru/ норматив-хокукый актлар яки аларның составында

мәҗбүри таләпләр булган аерым өлешләрен (аларны үтәүне бәяләү муниципаль контроль предметы булып тора), шулай ук тиешле норматив-хокукый актлар текстларын урнаштыруны тәэмин итә;

2) юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыра, шул исәптән, мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча эшләнмәләре чаралары белән һәм аларны бастырып, семинарлар һәм конференцияләр, масса-күләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре үткәреп һәм башка ысуллар белән. Мәҗбүри таләпләр үзгәргән очракта муниципаль контроль органы мәҗбүри таләпләрне билгеләүче, гамәлдәге актларга кергән үзгәрешләр, аларның үз көченә керү сроклары һәм тәртибе турында яңа норматив-хокукый актлар, шулай ук мәҗбүри таләпләрне кертүгә һәм үтәүгә юнәлдерелгән тиешле оештыру, техник чараларны үткәрү зарурлыгы турында комментарийлар әзерли һәм тарата;

3) муниципаль контроль эшчәнлеге өлкәсендә практиканы даими ( елына бер тапкырдан да ким түгел) гомумиләштерү һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru/ тиешле гомумиләштерүләрне урнаштыруны тәэмин итә, шул исәптән юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан шундый бозуларга юл куймау максатында кабул ителергә тиешле чараларга карата иң күп очрый торган мәҗбүри таләпләрне бозу очракларын күрсәтеп;

4) үз вәкаләтләре кысаларында, әгәр федераль закон тарафыннан башка тәртип билгеләнмәгән булса, мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында алдан кисәтүләр бирә.

1.12.2 Әгәр федераль закон тарафыннан башка нәрсә билгеләнмәгән булса, муниципаль контроль органында юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара элемтәсез генә гамәлгә ашырылучы контроль буенча чараларны тормышка ашыру барышында алынган әзерләнүче бозулар яки мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмә булганда яисә кергән мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда (авторлары расланмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалардан кала) булган, җирле үзидарә органнарыннан, масса-күләм мәгълүмат чараларыннан кергән мәгълүматларда, әгәр мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозу турында расланган мәгълүматлар булмаса, гражданнарның сәламәтлегенә, гомеренә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәният һәйкәлләре), дәүләт иминлегенә куркыныч тудырганда, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүгә китергән яисә турыдан-туры әлеге нәтиҗәләрнең куркынычлылыгын булдырган, һәм әгәр юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тиешле таләпләрне бозган өчен җавапка тартылмаган булсалар, муниципаль контроль органы юридик затка, шәхси эшмәкәргә мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында алдан кисәтү белдерә һәм юридик затка, шәхси эшмәкәргә мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу турыда алдан кисәтүдә күрсәтелгән срокта муниципаль контроль органына хәбәр итәргә тәкъдим итә.

Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында алдан кисәтүдә мәҗбүри таләпләргә туры килүче күрсәтмәләр, муниципаль хокукый актлар, норматив-хокукый акт белән билгеләнгән таләпләр, шулай ук юридик затның, шәхси эшмәкәрнең нинди гамәле (эшләмәве) әлеге таләпләрне бозуга китерергә мөмкин булуы турындагы мәгълүмат күрсәтелергә тиеш.

1.12.3. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара элемтәсез контроль буенча чаралар үз компетентлылыклары чикләрендә муниципаль контроль органының вәкаләтле вазифаи затлары тарафыннан муниципаль контроль органы җитәкчесе яки җитәкче урынбасары тарафыннан расланган шундый чараларны уздыру биремнәре нигезендә уздырыла.

1.12.4 Контроль буенча чаралар үткәргәндә әлеге Регламентның 1.12.1 пунктында күрсәтелгән мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозулар ачыкланган очракта, муниципаль контроль органының вәкаләтле вазифаи затлары үз компетентлылыклары чикләрендә шундый бозуларны кисәтү буенча чаралар күрәләр, шулай ук муниципаль контроль органы җитәкчесенә яки аның урынбасарына язма формада әлеге регламентның 2.3 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча юридик затка, шәхси эшмәкәргә планнан тыш тикшерүләр билгеләү зарурлыгы турындагы карар кабул итү өчен ачыкланган бозулар турында мәгълүмат белән күрсәтмә җибәрәләр.

1.12.5. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара элемтәсез контроль буенча чаралар үткәрү барышында әлеге регламентның 1.12.2 пунктында күрсәтелгән мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре яки әзерләнүче бозулар турында белешмә алган очракта, муниципаль контроль органы юридик затка, шәхси эшмәкәргә мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында алдан кисәтү җибәрә.

## II. **Контроль фнукцияләрен үтәү тәртибенә таләпләр**

2.1.Муниципаль контроль органы юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең үз эшчәнлекләрен башкарганда әлеге Регламентның1.2 нче пункты нигезендә муницпаль хокукый актлар таләпләрен үтәүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра. Контроль буенча чаралар аларны уздыруның еллык планы нигезендә гамәлгә ашырылучы, муницпаль контроль органы җитәкчесе раслаган планлы тикшерүләр формасында, шулай ук закон нигезендә оешмаларның һәм гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәп, планнан тыш формада гамәлгә ашырыла.

2.2. Юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең үз эшчәнлекләрен башкару процессында мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне үтәве, шулай ук эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен башкара башлау турындагы хәбәрдәге белешмәнең муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләргә туры килүе.

Муниципаль контроль органын тикшерүнең еллык планы планлы тикшерү уздыру өчен нигез булып тора.

Планлы тикшерү уздыруның еллык планына планлы тикшерү уздыруы кертү өчен түбәндәге көннән өч ел узу нигез булып тора:

1) юридик затны, шәхси эшмәкәрне дәүләт теркәве;

2) юридик затны, шәхси эшмәкәрне соңгы планлы тикшерү үткәрүнең тәмамлануы;

3) Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләте белән башкарма властеның тиешле федераль органы өлкәсенә эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында бирелгән белдерүе нигезендә юридик затның, шәхси эшмәкәрнең эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау көненнән.

Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы муниципаль контроль органы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.

Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы кызыксынучан кешеләргә аны муниципаль контроль органының рәсми сайтында урнаштыру чаралары белән (яисә башка ысул белән) җиткерелә.

Муниципаль контроль органы тарафыннан юридик затка, шәхси эшмәкәргә планлы тикшерү үткәрү турында аны уздыру башланганчы өч көн алдан муниципаль контроль органы җитәкчесе, аның урынбасарының планлы тикшерү үткәрү башлануы турындагы боерыгы күчермәсен почта аша тапшыру турында белдерү белән яки электрон документ чаралары, көчле квалификацияле электрон имза белән кул куелган һәм юридик затның, шәхси эшмәкәрнең электрон почта адресы аша җибәрелгән ( әгәр шундый адрес юридик затның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында булса, яисә алданрак муниципаль контроль органына юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан яки башка ысул белән бирелгән булса) чаралар белән хәбәр ителә.

Тикшерүләрнең еллык планына кертү өчен чикләүләр:

-планлы тикшерү юридик зат, шәхси эшмәкәр дәүләт теркәве үткән вакыттан өч ел узганнан соң үткәрелергә мөмкин;

-бер юридик затка яки шәхси эшмәкәргә карата планлы тикшерү өч елга бер тапкырдан да артык үткәрелми ( эшчәнлекләрен сәламәтлек саклау, мәгариф һәм социаль өлкәдә тормышка ашыручы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрдән кала)

Юридик затларны (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур подразделениеләре) һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы тикшерүлүр үткәрүнең еллык планында түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) эшчәнлекләре планлы тикшерелергә тиешле юридик затларның (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур подразделениеләре) исемнәре, шәхси эшмәкәрләрнең фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, юридик затларның (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур подразделениеләренең) булу урыннары яки шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлекләрен гамәлгә ашыруның факттагы урыны;

2) һәр планлы тикшерү үткәрүнең максаты һәм нигезе;

3) һәр планлы тикшерүне башлау көне һәм сроклары;

4) төгәл бер планлы тикшерү уздыручы дәүләт контроле органы (күзәтчелек) яки муниципаль контроль орган исеме. Дәүләт контроле органнары (күзәтчелек), муниципаль контроль органнарының бергәләшеп планлы тикшерү үткәргәндә шундый тикшерүдә катнашучы органнарның барысының да исемнәре күрсәтелә.

2.3. Планнан тыш тикшерү предметы булып юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең үз эшчәнлекләрен башкару процессында мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне үтәве, дәүләт контроле органнары (күзәтчелек), муниципаль контроль органнары күрсәтмәләрен үтәве, гражданнарның сәламәтлегенә, гомеренә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясенең Музей фонды составына кертелгән аеруча кыйммәтле булган, шул исәптән уникаль музей әйберләренә һәм предметларына, зарар китерү буенча чаралар уздыру, Россия Федерациясенең Архив фонды документларына, аерым тарихи, фәнни, мәдәни билгеләнештәге, милли китапханәләр фонды составына керүче документларга, дәүләт иминлеген тәэмин итү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне кисәтү, шундый зыян китерү нәтиҗәләрен бетерү буенча чаралар уздыру тора.

Планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез булып торалар:

1) юридик затның, шәхси эшмәкәрнең мәҗбүри таләпләрне һәм (яки) муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозуларны бетерү турындагы алдан бирелгән күрсәтмәләрне үтәү срогының чыгуы;

1.1) муниципаль контроль органына юридик заттан яки шәхси эшмәкәрдән хокукый статус, эшчәнлекнең аерым төрләрен тормышка ашыру хокукына махсус рөхсәт (лицензия) бирү турында, яки башка юридик әһәмияттәге гамәлләрне тормышка ашыруга рөхсәт ( килешү) алуга, әгәр юридик затка, шәхси эшмәкәргә планнан тыш тикшерү уздыру хокукый статус, махсус рөхсәт (лицензия), рөхсәт (килешү) кагыйдәләре белән каралган булса, гариза кергәндә;

2) юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара контроль буенча чаралар нәтиҗәләренә анализ йомгагы буенча вазифаи затның дәлилләнгән күрсәтмәсен карау яки муниципаль контроль органына гражданнардан, шул исәптән) юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән кергән гаризаларны алдан тикшерү, дәүләт власте, җирле үзидарә органнарыннан, масса-күләм мәгълүмат чараларыннан кергән түбәндәге фактлар турындагы мәгълүмат:

а) гражданнарның сәламәтлегенә, гомеренә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясенең Музей фонды составына кертелгән аеруча кыйммәтле булган, шул исәптән уникаль музей әйберләренә һәм предметларына, Россия Федерациясенең Архив фонды документларына, аерым тарихи, фәнни, мәдәни билгеләнештәге, милли китапханәләр фонды составына керүче документларга, дәүләт иминлеген тәэмин итүгә зарар китерү куркынычы барлыкка килгәндә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы булганда;

б) гражданнарның сәламәтлегенә, гомеренә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясенең Музей фонды составына кертелгән аеруча кыйммәтле булган, шул исәптән уникаль музей әйберләренә һәм предметларына, Россия Федерациясенең Архив

фонды документларына, аерым тарихи, фәнни, мәдәни билгеләнештәге, милли китапханәләр фонды составына керүче документларга, дәүләт иминлеген тәэмин итүгә зарар китерү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү;

в) кулланучыларның хокукын бозу (әгәр кулланучыларның, гражданнарның хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеге органына мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүче юридик затка, шәхси эшмәкәргә үзенең бозылган хокукларын яклау (торгызу) өчен мөрәҗәгать иткән һәм гариза бирүченең шундый мөрәҗәгате яисә таләпләре канәгатьләндерелмәгән булса);

г) товарларны маркировклау таләпләрен бозу;

з) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарны үтәү өчен күзәтчелек кысаларында планнан тыш тикшерүләр уздыру турында прокурор таләбе;

Муниципаль контроль органына мөрәҗәгать иткән затны ачыклау мөмкинлеге бирмәүче мөрәҗәгать һәм гариза, шулай ук эчтәлегендә әлеге регламентның 2.3 нче пунктындагы бишенче абзацтан сигезенче абзацка кадәр күрсәтелгән фактлар турында белешмә булмаган мөрәҗәгать һәм гариза планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып тормый. Әгәр мөрәҗәгатьтә һәм гаризада язылган хәбәр әлеге регламентның алда күрсәтелгән пунктына туры килсә, әлеге очрак планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып тора, муниципаль контроль органының вазифаи заты мөрәҗәгать яки гариза авторлыгына нигезләнгән шөбһәсе булса, мөрәҗәгать иткән затны ачыклау өчен чаралар күрергә тиеш. Гариза бирүче тарафыннан электрон документ формасында җибәрелгән мөрәҗәгать һәм гариза түбәндәге шарт булганда гына планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып тора, алар гариза бирүче тарафыннан идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасында гариза бирүчене мәҗбүри авторизацияләү каралган мәгълүмати-коммуникацион технология чараларыннан файдаланып җибәрелгән булса.

Планнан тыш тикшерү документлар буенча тикшерү һәм (яки) күчмә тикшерү формасында уздырыла.

Юридик затларны, Россия Федерациясе законнары нигезендә кече яки урта эшмәкәрлек субъектларына караучы шәхси эшмәкәрләрне планнан тыш күчмә тикшерү муниципаль контроль органнары тарафыннан әлеге пунктның дүртенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән сәбәпләр буенча, шундый юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлекне тормышка ашыру урыны буенча прокуратура органы белән килештереп үткәрелергә мөмкин.

Әгәр планнан тыш күчмә тикшерү уздыру өчен гражданнарның сәламәтлегенә, гомеренә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясенең Музей фонды составына кертелгән аеруча кыйммәтле булган, шул исәптән уникаль музей әйберләренә һәм предметларына, Россия Федерациясенең Архив фонды документларына, аерым тарихи, фәнни, мәдәни билгеләнештәге, милли китапханәләр фонды составына керүче документларга, дәүләт иминлеген тәэмин итүгә зарар китерү куркынычы барлыкка килү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы

гадәттән тыш хәлләр куркынычы булу, мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар тарафыннан билгеләнгән таләпләрне бозуларны ачыклау сәбәп булып торса, шундый бозуларны кылу вакытына кичектергесез чаралар кабул итү заруры уңаеннан дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары әлеге маддәнең 6 һәм 7нче өлешләрендә каралган документларны җибәрү чарасы белән контроль буенча чаралар уздыру турында прокуратура органнарына (егерме дүрт сәгать эчендә) тиз арада хәбәр итеп, планнан тыш күчмә тикшерү башларга хокуклылар. Бу очракта прокурор яки аның урынбасары тиешле документлар кергән көнне планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында карар кабул итә.

Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы җитәкчесе, җитәкче урынбасары юридик затны, шәхси эшмәкәрне планнан тыш күчмә тикшерү турындагы боерыкка яки әмергә кул куйган көнне, аны үткәрүне килештерү максатында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы почта аша тапшыру турында белдерү белән яки көчле квалификацияле электрон имза белән кул куелган электрон документ формасында хәбәр җибәрәләр. Әлеге гаризага планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы җитәкчесе, җитәкче урынбасары боерыгы яки әмере күчермәләре һәм аны үткәрү өчен нигез булган эчтәлектәге белешмә булган документлар беркетелә.

Прокурорның яки аның урынбасарының планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү яки аны үткәрүне килештерүдән баш тарту турындагы карарына югарыгы прокурорга яки судка шикаять бирергә мөмкин.

Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында, планнан тыш күчмә тикшерүдән кала, аны үткәрү әлеге маддәнең 2 нче өлешендәге 2 нче пунктында күрсәтелгән, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы тарафыннан юридик затка, шәхси эшмәкәргә аны үткәрү башланганчы егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча мөмкин булган теләсә нинди ысул белән, шул исәптән көчле квалификацияле электрон имза белән кул куелган электрон документ ысулы белән һәм юридик затның, шәхси эшмәкәрнең электрон почта адресы буенча хәбәр җибәрелә, әгәр шундый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында булса яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына, муниципаль контроль органына элегрәк бирелгән булса.

Әгәр юридик затның, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеге нәтиҗәсендә гражданнарның сәламәтлегенә, гомеренә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясенең Музей фонды составына кертелгән аеруча кыйммәтле булган, шул исәптән уникаль музей әйберләренә һәм предметларына, Россия Федерациясенең Архив фонды документларына, аерым тарихи, фәнни, мәдәни билгеләнештәге, милли китапханәләр фонды составына керүче документларга, дәүләт иминлеген тәэмин итүгә зарар китерү куркынычы барлыкка килү, шулай ук табигый һәм техноген

характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы булса яки барлыкка килсә, юридик затны, шәхси эшмәкәрне планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне башлау өчен алдан хәбәр итү таләп ителми.

Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен сәбәпләргә бәйсез рәвештә аны үткәрү әлеге регламент белән билгеләнгән тикшерү үткәрү тәртибенә тәңгәл килә.

Юридик затның, шәхси эшмәкәрнең тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган муниципаль хокукый актлар таләпләрен бозуларны бетерү буенча күрсәтмәләрне үтәвенә планнан тыш тикшерү катгый рәвештә күрсәтмә тәэсире беткәнче уздырыла, срок күрсәтмә юридик затка, шәхси эшмәкәргә керү көненнән башлап исәпләнә.

2.4. Һәр тикшерүнең дәвамлылыгы 20 эш көненнән артмаска тиеш.

2.4.1.Кече эшмәкәрлекнең бер субъектына карата планлы күчмә тикшерү үткәрүнең гомуми срогы кече предприятие өчен елына 50 сәгатьтән һәм микропредприятие өчен 15 сәгатьтән артмаска тиеш.

2.4.2. Кирәк булганда әлеге регламентның 2.4.1. пунктында күрсәтелгән тикшерүне үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати үзара элемтә кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүмат алу муниципаль контроль органы җитәкчесе тарафыннан ведомствоара мәгълүмати үзара элемтәне тормышка ашыру өчен кирәк булган срокка туктатылырга мөмкин, әмма ун эш көненнән артыграк түгел. Тикшерү үткәрүне икенче тапкыр туктатуга юл куелмый.

Тикшерү үткәрүне туктату срогы гамәлдә булган чорга муниципаль контроль органының территорияләрдә, биналарда, каралтыларда, корылмаларда, кече эшмәкәрлек субъектларының башка объектларында күрсәтелгән тикшерү белән бәйле йогынтысы туктатыла.

2.4.3.Катлаулы һәм (яки) озакка сузылган тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм тикшеренүләр үткәрү зарурлыгы белән бәйле очраклардан кала, күчмә планлы тикшерү үткәрүче муниципаль контроль органының вазифаи затларының сәбәпле тәкъдимнәре нигезендә шундый орган җитәкчесе тарафыннан күчмә планлы тикшерү үткәрү срогы арттырылырга мөмкин, әмма егерме эш көненнән дә күбрәккә түгел, кече предприятиеләргә карата илле сәгатьтән, микропредприятиеләргә карата унбиш сәгатьтән артмаска тиеш.

2.5.Контроль буенча чараларда тиешле анализлар, караулар үткәрү һәм нәтиҗәләр бирү өчен җәлеп ителә торган экспертларның, эксперт оешмаларының катнашуы карала:

- муниципаль контроль органы җитәкчесе, аның урынбасары карары белән;

- килешү нигезендә, ул муниципаль контроль органы белән төзелә һәм тиешле өлкәдә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча функцияләрне үтәүгә бүлеп бирелүче акчадан җирле бюджет акчасы хисабына финанслана.

Документлар буенча тикшерү предметы булып торалар: юридик затның, шәхси эшмәкәрнең оештыру-хокукый формасы, хокуклары һәм вазифаларын билгеләүче документларда булган белешмәләр һәм аларның эшчәнлеген гамәлгә ашырганда кулланыла торган һәм аларның мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнүче таләпләрне үтәү белән бәйле документлар, муниципаль контроль органы күрсәтмәләрен һәм карарларын үтәү.

Документлар буенча тикшерү үткәрү процессында вазифаи затлар беренче чиратта юридик затның, шәхси эшмәкәрнең муниципаль контроль органы карамагында булган документларны карый, шул исәптән 26.12.2008 елда кабул ителгән 294 нче Федераль законның 8 нче маддәсе белән билгеләнгән тәртиптә бирелгән эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турындагы белдерү, алдан булган тикшерүләр актлары, административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау документлары һәм юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата муниципаль контроль органы башкарган нәтиҗәләр турындагы башка документлар.

Әгәр муниципаль контроль органы карамагындагы документларда булган белешмәләрнең дөреслеге шик тудырса яисә әлеге белешмәләр юридик затның, шәхси эшмәкәрнең мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнүче таләпләрне үтәүне билгеләү мөмкинлеге бирмәсә, муниципаль контроль органы юридик зат адресына, шәхси эшмәкәр адресына документлар буенча тикшерү барышында карау өчен кирәк булган башка документларны тәкъдим итүне таләп итеп, сәбәбе күрсәтелгән сорау җибәрә. Әлеге сорауга документлар буенча тикшерү үткәрү турындагы муниципаль контроль органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) боерыгы яки әмеренең мөһер белән расланган күчермәсе беркетелә.

Сәбәбе күрсәтелгән сорауны алганнан соң юридик зат, шәхси эшмәкәр 10 эш көне эчендә муниципаль контроль органына сорауда күрсәтелгән документларны җибәрергә тиеш.

Сорауда күрсәтелгән документлар мөһер белән расланган (әгәр ул булса) күчермә төрендә бирелә һәм шул рәвешле шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең башка вазифаи затының имзасы куелган булырга тиеш. Юридик зат, шәхси эшмәкәр сорауда күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куеп, электрон документлар формасында тәкъдим итәргә хаклы.

Әгәр Россия Федерациясе законы белән каралмаган булса, муниципаль контроль органына бирелә торган документларның күчермәләрен нотариаль раслатуны таләп итүгә юл куелмый.

Документлар буенча тикшерү барышында юридик зат, шәхси эшмәкәр биргән документларда хаталар һәм (яки) каршылыклар ачыкланса яисә әлеге документлардагы һәм (яки) муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында алынган документлардагы белешмәләр муниципаль контроль органындагы документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, бу турыда юридик затка, шәхси эшмәкәргә 10 эш көне эчендә язма формада аңлатма бирүне таләп итеп мәгълүмат җибәрелә.

Муниципаль контроль органына ачыкланган хаталар һәм (яки) бирелгән документлардагы каршылыклар яисә белешмәләрнең тәңгәл килмәве турында аңлатма биргән юридик зат, шәхси эшмәкәр өстәмә рәвештә муниципаль контроль органына алдан тапшырылган документларның дөреслеген раслаучы документлар тәкъдим итәргә хокуклы.

Документлар буенча тикшерү үткәрүче вазифаи зат юридик зат җитәкчесе яки башка вазифаи зат, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле биргән

аңлатмаларны һәм алдан тапшырылган документларның дөреслеген раслаучы документларны карарга тиеш. Әгәр бирелгән аңлатмаларны һәм документларны караганнан соң яисә аңлатмалар булмаганда муниципаль контроль органы мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнүче таләпләрне бозу билгеләрен ачыкласа, муниципаль контроль органының вазифаи заты күчмә тикшерү үткәрергә хокуклы.

Документлар буенча тикшерү үткәргәндә муниципаль контроль органының юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән документлар буенча тикшерү предметына карамый торган белешмәләр һәм документлар, шулай ук башка муниципаль контроль органнарыннан әлеге орган тарафыннан алынырга мөмкин булган документларны һәм белешмәләрне таләп итәргә хакы юк.

2.6. Юридик затның, шәхси эшмәкәрнең документларында булган белешмәләр, шулай ук аларның хезмәткәрләренең туры килүе, күрсәтелгән затлар тарафыннан эшчәнлек тормышка ашырылганда файдаланыла торган территорияләрнең, биналарның, корылмаларның, каралтыларның, җиһазларның, шундый объектларның, транспорт чараларының, юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан җитештерелә һәм сатыла торган товарларның ( башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр) торышы һәм алар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнүче таләпләрне үтәү буенча кабул ителгән чаралар күчмә тикшерү предметы булып тора.

Күчмә тикшерү документлар буенча тикшерү мөмкин булмаган очракта үткәрелә:

1) юридик затның, шәхси эшмәкәрнең муниципаль контроль органы карамагында булган башка документларда һәм эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турындагы хәбәрдәге белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген раслау;

2) контроль буенча тиешле чараларны үткәрмичә генә юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнүче таләпләргә тәңгәл килүен бәяләргә.

Күчмә тикшерү муниципаль контроль органының вазифаи затлары тарафыннан хезмәткәр таныклыгын күрсәтүдән, юридик зат җитәкчесен яки аның вазифаи затын, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен муниципаль контроль органы җитәкчесенең, җитәкче урынбасарының күчмә тикшерү билгеләү турындагы боерыгы яки әмере һәм күчмә тикшерү үткәрүчеләрнең вәкаләтләре, шулай ук максатлары, бурычлары, күчмә тикшерү үткәрү өчен нигезләр, контроль буенча чараларның төрләре һәм күләме, күчмә тикшерүгә җәлеп ителгән экспертлар составы, эксперт оешмалары вәкилләре, аны үткәрү сроклары һәм шартлары белән таныштырудан башлана.

Юридик зат җитәкчесе, аның вазифаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле күчмә тикшерү үткәрүче муниципаль контроль органының вазифаи затларына максатлары, бурычлары белән бәйле һәм күчмә тикшерү предметы булган документлар белән танышу мөмкинлеге бирергә тиешләр, әгәр күчмә тикшерү алдыннан документлар буенча тикшерү үтмәгән булса, шулай ук күчмә тикшерү үткәрүче вазифаи затларның һәм күчмә тикшерүдә катнашучы экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең

юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан эшчәнлекне тормышка ашырганда файдаланыла торган территорияләргә, биналарга, корылмаларга, каралтыларга керүен, җиһазлардан, шундый объектлардан, транспорт чараларыннан һәм алар ташый торган йөкләрдән файдалануын тәэмин итәргә.

2.7. Юридик зат җитәкчесе, аның вазифаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиленең тикшерү үткәргәндә түбәндәге хокуклары бар:

1) тикшерү үткәргәндә турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына карата сораулар буенча аңлатма бирергә;

2) муниципаль контроль органыннан, аның вазифаи затларыннан тикшерү предметына карый торган һәм аны тәкъдим итү әлеге Федераль закон белән каралган мәгълүматны алырга;

3) муниципаль контроль органы тарафыннан ведомствоара мәгълүмати үзара элемтә кысаларында башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә җирле үзидарә оешмалары ведомствосында булган органнардан (әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат алар карамагында) алынган документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән танышырга;

4) ведомствоара мәгълүмати үзара элемтә кысаларында соратыла торган документларны һәм (яки) мәгълүматларны үз инициативалары буенча муниципаль контроль органына тапшыру;

5) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында үзеңнең тикшерү нәтиҗәләре белән танышуыңны, алар белән, шулай ук муниципаль контроль органының вазифаи затларының аерым гамәлләре белән килешүеңне яки килешмәвеңне күрсәтергә кирәк;

6) муниципаль контроль органының вазифаи затларының тикшерү үткәргәндә юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын бозуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Россия Федерациясе законы нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерергә;

7) тикшерүдә катнашуга эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы вәкаләтле вәкилне яисә Россия Федерациясе субъектларында эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне җәлеп итәргә.

## III. Административ процедуралар

3.1. Муниципаль контрольне үткәрү буенча фунцияләрне гамәлгә ашыру үз эченә түбәндәге процедураларны ала:

-контроль буенча чаралар үткәрү турында карар кабул итү;

- контроль буенча чаралар әзерләү һәм тикшерелә торган оешмага хәбәр итү;

-контроль буенча чаралар үткәрү;

-кушымталар (алар булганда) күчермәләре белән актны рәсмиләштерү һәм тапшыру;

-күрсәтмәне рәсмиләштерү һәм бирү.

3.2. Тикшерү муниципаль контроль органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) боерыгы яки әмере нигезендә үткәрелә.

Тикшерү бары тик муниципаль контроль органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) боерыгында яки әмерендә күрсәтелгән вазифаи затлар тарафыннан гына үткәрелергә мөмкин.

Муниципаль контроль органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) боерыгында яки әмерендә күрсәтелә:

1) муниципаль контроль органы исеме, шулай ук муниципаль контроль төрләре;

2) вазифаи затларның яки тикшерү үткәрүгә вәкаләте булган, вазифаи затлар вәкилләренең, тикшерү үткәрүгә җәлеп ителүче экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, вазифалары;

3) тикшерү үткәрелүче юридик затның исеме яки шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик затның ( аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур подразделениеләренең урнашу урыны) яки шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлекләрен фактта гамәлгә ашыру урыны;

4) тикшерүнең максатлары, бурычлары, тикшерү предметы һәм аны үткәрү срогы;

5) тикшерү үткәрүнең хокукый нигезләре;

5.1) тикшерелергә тиешле мәҗбүри таләпләр һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр;

6) тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен кирәк булган контроль буенча чаралар исемлеге һәм үткәрү сроклары;

7) муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентлар исемлеге;

8) юридик зат, шәхси эшмәкәр тапшырырга тиешле тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен кирәк булган документлар исемлеге;

9) тикшерү үткәрүне башлау һәм тәмамлау көне;

10) башка белешмәләр, әгәр алар дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль органы җитәкчесе, җитәкче урынбасары боерыгының типовой формасы белән каралган булса.

3.3. Муниципаль контроль органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасары) мөһер белән расланган боерыгы яки әмере күчермәсе тикшерү үткәргән муниципаль контроль органының вазифаи заты имзасы белән юридик зат җитәкчесенә, башка вазифаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә бер үк вакытта хезмәт таныклыгын күрсәтеп тапшырыла. Тикшерелергә тиешле затларның таләбе буенча муниципаль контроль органының вазифаи заты үзенең вәкаләтләрен раслау максатында әлеге органнар турында мәгълүмат та бирергә тиеш.

3.4. Юридик зат җитәкчесе, аның башка вазифаи заты яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле соравы буенча муниципаль контроль органының вазифаи затлары тикшерелергә тиешле затларны контроль буенча чаралар үткәрүнең административ регламенты һәм

юридик зат файдалана торган, шәхси эшмәкәр эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган объектларда аларны үткәрү тәртибе белән таныштырырга тиеш.
3.5. Муниципаль контроль органының вазифаи затлары тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:
1) мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозуны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау буенча Россия Федерациясе законы нигезендә бирелгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы күләмдә башкарырга тиешләр;
2) Россия Федерациясе законы нигезендә тикшерү үткәрелә торган юридик затның, шәхси эшмәкәрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;
3) муниципаль контроль органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) тикшерүне билгеләү шул рәвешчә аны үткәрү турындагы боерыгы яки әмере нигезендә тикшерү үткәрергә;
4) тикшерүне хезмәт бурычларын үтәгән вакытта гына үткәрергә, күчмә тикшерүне хезмәткәр таныклыгын, муниципаль контроль органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасары) боерыгы яки карары күчермәсе тәкъдим итеп, әлеге Регламентның 2.3нче пунктындагы дүртенче, бишенче, алтынчы абзацлар белән каралган очракта тикшерү үткәрүне килештерү турындагы документ күчермәсе белән;
5) тикшерү үткәргән вакытта юридик зат җитәкчесенең, аның башка вазифаи затының яки юридик затның вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең катнашуына каршы төшмәскә һәм тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;
6) тикшерү үткәргәндә катнашучы юридик зат җитәкчесенә, аның башка вазифаи затына яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына кагылышлы мәгълүматны һәм документларны тәкъдим итәргә тиешләр;
7) юридик зат җитәкчесен, аның башка вазифаи затын яки юридик затның вәкаләтле вәкилен, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;
7.1) юридик зат җитәкчесен, аның башка вазифаи затын яки юридик затның вәкаләтле вәкилен, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати үзараэлемтә кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштырырга;
8) ачыкланган бозулар фактлары буенча кабул ителә торган чараларны билгеләгәндә аларның кешеләр тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохитка, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясенең Музей фонды составына кертелгән музей әйберләренә һәм

музей коллекцияләренә, Россия Федерациясенең Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, аерым тарихи, фәнни, мәдәни билгеләнешкә ия булган, милли китапханәләр фондына керүче документларга, дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт һәм муниципаль мөлкәткә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга потенциаль куркыныч тудыруын исәпкә алырга, шулай ук гражданнарның, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезләнмәгән чикләүне булдырмаска;

9) аларга юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан шикаять белдерелгәндә Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән тәртиптә үз гамәлләреңнең нигезлелегеген расларга;

10) әлеге Регламент белән билгеләнгән тикшерү срокларын үтәргә;

11) юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән Россия Федерациясе законы белән каралмаган документлар һәм башка белешмәләр таләп итмәскә;

12) юридик зат җитәкчесе, аның башка вазифаи заты яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле соравы буенча күчмә тикшерү үткәрүне башлар алдыннан аларны (әгәр ул булса) Административ регламент нигезләмәләре (тикшерү аның нигезендә үткәрелә) белән таныштырырга;

13) тикшерү үткәрү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналына язарга, әгәр юридик затта, шәхси эшмәкәрдә ул булса;

3.6. Тикшерү үткәргәндә муниципаль контроль органының вазифаи затларының түбәндәгеләрне башкарырга хокуклары юк:

1) мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне үтәүне тикшерергә, әгәр шундый таләпләр муниципаль контроль органы вәкаләтләренә карамаса, әлеге вазифаи затлар шушы орган исеменнән эшли;

1.1) СССР һәм РСФСРның башкарма власть органнарының норматив-хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләрне үтәүне тикшерергә, шулай ук куллану Россия Федерациясе законы белән каралмаган норматив документлар, йөкләмәләр таләпләрен үтәүне тикшерергә;

1.2) Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән тәртиптә бастырылмаган мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

2) әгәр аны үткәргән вакытта юридик зат җитәкчесе, аның башка вазифаи заты яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмаса, планлы яки планнан тыш күчмә тикшерү башкарырга, әлеге регламентның 2.3нче пунктындагы бишенче абзацтан сигезенче абзацка кадәр каралган нигезләр буенча шундый тикшерү үткәрү очракларыннан кала, шулай

ук жир участоклары хуҗаларына, җирдән файдаланучыларга, җирләр биләүчеләргә һәм җир участоклары арендаторларына тиешле хәбәрне җиткергән очракта җир законы таләпләрен үтәүне тикшерергә;
3) әйләнә-тирә мохит объектларын һәм производство мохиты объектларын тикшерү пробалары, продукцияләр үрнәкләре, мәгълүматлар, документлар таләп итәргә; әгәр алар тикшерү объектлары булып тормасалар һәм тикшерү предметына карамасалар, шулай ук шундый документларның төп нөсхәләрен алырга;
4) күрсәтелгән үрнәкләрне алу турындагы беркетмәләрне рәсмиләштермичә аларга тикшерү, сынаулар, үлчәүләр үткәрү өчен әйләнә-тирә мохит объектларын һәм производство мохиты объектларын тикшерү пробаларын, продукцияләр үрнәкләрен тартып алырга ,билгеләнгән форма һәм сан буенча милли стандартлар, үрнәкләрне сайлап алу кагыйдәләре буенча билгеләнгән нормадан артып киткән, аларны тикшерү, сынау, үлчәү алымнары, техник регламентлар һәм үз көченә керү көненә кадәр гамәлдә булган башка норматив-техник документлар һәм тикшерү, сынау, үлчәү кагыйдәләре һәм алымнары белән билгеләнгән продукцияләр үрнәкләрен алырга;
5) тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерцияви, хезмәт һәм закон тарафыннан саклаучы башка серне тәшкил иткән мәгълүматны таратырга, Россия Федерациясе законы белән каралган очраклардан кала;
6) тикшерү үткәрүнең билгеләнгән срокларын арттырырга;
7) юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә алар хисабына контроль буенча чаралар үткәрү турында күрсәтмәләрне яки тәкъдимнәрне бирүне гамәлгә ашырырга;
8) юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән документларны һәм (яки) мәгълүматларны бирүне таләп итәргә, җирле үзидарәнең башка органнары яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән җирле үзидарә оешмалары органнары ведомствосы карарында булган рөхсәт итү документларын да кертеп;
9) юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән тикшерү үткәрү башлану көненә кадәр документларны, мәгълүматларны бирүне таләп итәргә. Муниципаль контроль органы тикшерү үткәрү турында боерык яки карар кабул иткәннән соң кирәкле ведомствоара мәгълүмати үзараэлемтә кысаларында документларны һәм (яки) мәгълүматны соратып алырга хаклы.
3.7. Тикшерү үткәргән муниципаль контроль органы вазифаи затлары тарафыннан тикшерү нәтиҗәләре буенча билгеләнгән формада ике данәдә акт төзелә.
Тикшерү актында түбәндәгеләр күрсәтелә:
1)тикшерү актын төзү көне, вакыты һәм урыны;

2) муниципаль контроль органы исеме;
3) муниципаль контроль органы җитәкчесе, җитәкче урынбасары боерыгы яки карары көне һәм номеры;
4) тикшерү үткәргән вазифаи затның яки вазифаи затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазифасы;
5) тикшерелә торган юридик затның исеме яки шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, шулай ук тикшерү үткәргәндә катнашкан юридик зат җитәкчесенең, башка вазифаи затның яки вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазифасы;
6) тикшерү үткәрү көне, вакыты, дәвамлылыгы һәм урыны;
7) тикшерү нәтиҗәләре турында белешмә, шул исәптән ачыкланган мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозулар, аларның характерлары турындагы һәм күрсәтелгән бозуларга юл куйган затлар турындагы белешмәләр;
8) тикшерү үткәргәндә катнашкан юридик зат җитәкчесенең, башка вазифаи затның яки вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең тикшерү акты белән танышуы яки танышудан баш тартуы турындагы, аларның имзалары булу яки имза куюдан баш тартулары турындагы белешмә, шулай ук үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналына кертү турындагы яисә юридик затта, шәхси эшмәкәрдә күрсәтелгән журнал булмау сәбәпле, шундый язуны кертү мөмкинлеге булмау турында белешмә;
9) тикшерү үткәргән вазифаи затның яки вазифаи затларның имзалары.

Тикшерү актына продукция үрнәкләрен алу, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм производство мохиты объектларын тикшерү пробалары беркетмәләре, үткәрелгән тикшерүләр, сынаулар һәм экспертизалар беркетмәләре яки нәтиҗәләре, юридик зат хезмәткәрләре, шәхси эшмәкәр эшчеләре аңлатмалары, аларга мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнгән, ачыкланган бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләр һәм тикшерү нәтиҗәләре белән бәйле башка документлар һәм аларның күчермәләре беркетелә.

Тикшерү акты турыдан-туры ул тәмамланганнан соң ике данәдә рәсмиләштерелә, аларның берсе кушымталар күчермәләре белән тикшерү акты белән танышу яки танышудан баш тарту турында имза куйдыртып, юридик зат җитәкчесенә, аның башка вазифаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә тапшырыла. Юридик зат җитәкчесе, аның башка вазифаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган зат тикшерү акты белән танышу яки танышудан баш тарту турында расписка бирүдән баш тарткан очракта, акт тапшыру турында белдерү белән заказлы итеп почта аша җибәрелә.

Ул муниципаль контроль органы эшендә сакланучы тикшерү акты данәсенә беркетелә.Тикшерелүче зат муниципаль контроль кысаларында үзара элемтәнең электрон формасын гамәлгә ашыруга ризалашканда тикшерү акты әлеге актны төзегән затның көчле квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ формасында юридик зат җитәкчесенә, аның башка вазифаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта тикшерелүче затка әлеге документны алуны раслауны тәэмин итүче ысул белән актны төзегән затның көчле квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ формасында җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип исәпләнә.

Әгәр тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар, махсус тикшерүләр, экспертизалар йомгаклары буенча нәтиҗә алу зарури булганда, тикшерү акты контроль буенча чараларны тәмамлаганнан соң өч эш көненнән артмаган срокта төзелә һәм юридик зат җитәкчесенә, аның башка вазифаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә имза куйдырып тапшырыла яисә тапшыру турында белдерү белән заказлы итеп почта аша һәм (яки) әлеге актны төзегән затның көчле квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ формасында (тикшерелүче зат муниципаль контроль кысаларында үзара элемтәнең электрон формасын гамәлгә ашыруга ризалашкан очракта) әлеге документны алуны раслауны тәэмин итүче ысул белән җибәрелә. Шул ук вакытта тапшыру турындагы белдерү һәм (яки) әлеге документны алуны башка раслаучы хәбәр муниципаль контроль органы эшендә сакланучы тикшерү акты данәсенә беркетелә.

Әгәр планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен аны үткәрүне прокуратура органы белән килештерү таләп ителсә, тикшерү акты күчермәсе тикшерү үткәрүне килештерү турында карар кабул иткән прокуратура органына тикшерү акты төзелгән көннән соң биш эш көне эчендә җибәрелә.

Дәүләт, коммерцияви, хезмәт һәм башка сердән торган эчтәлектәге мәгълүмат булган тикшерү нәтиҗәләре Россия Федерациясе законында каралган таләпләрне үтәп рәсмиләштерелә.

Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле башкарма властеның федераль органы белән билгеләнгән типовой формада тикшерүләрне исәпкә алу журналы алып барырга хокуклы.

Тикшерүләрне исәпкә алу журналында муниципаль контроль органының вазифаи затлары тарафыннан эчтәлегендә муниципаль контроль органы исеме, тикшерү үткәрүнең башлану һәм тәмамлану көннәре, аны үткәрү вакыты, хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм тикшерү предметы, ачылган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турында белешмә булган үткәрелгән

тикшерү турында язма булдырыла, шулай ук тикшерү үткәргән вазифаи затның яки вазифаи затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазифасы күрсәтелә. Тикшерүләрне исәпкә алу журналы тегелергә, аңа номер сугылырга һәм юридик затның, шәхси эшмәкәрнең (әгәр мөһере булса) мөһере белән расланырга тиеш.

Тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаса, тикшерү актында тиешле язу языла.

Тикшерү үткәрелгән юридик зат, шәхси эшмәкәр тикшерү актында язылган фактлар, чыгарылмалар, тәкъдимнәр белән яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәләр белән килешмәсә, тикшерү актын алган көннән алып унбиш көн эчендә муниципаль контрольнең тиешле органына язма формада тикшерү актының һәм ( яки) ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәнең тулаем яки аерым нигезләмәләренә карата дәгъва белдерергә хаклы. Шуның белән бергә юридик зат, шәхси эшмәкәр шундый дәгъваларга әлеге дәгъваларның нигезлеген раслаучы документлар яки аларның раслатылган күчермәләрен беркетергә яисә килешенгән срокта аларны муниципаль контроль органына тапшырырга тиешләр. Күрсәтелгән документлар тикшерелүче затның көчле квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документлар формасында ( электрон документлар пакеты) җибәрелергә мөмкин.

3.8.Тикшерү үткәргән вакытта юридик затның, шәхси эшмәкәрнең мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозулары ачыкланганда, тикшерү үткәргән дәүләт контроле органының (күзәтчелек), муниципаль контроль органының вазифаи затлары Россия Федерациясе законында каралган вәкаләтләр чикләрендә түбәндәгеләрне эшләргә тиешләр:

1) юридик затка, шәхси эшмәкәргә ачыкланган бозуларны бетерү турында аларны бетерү срокларын күрсәтеп һәм (яки) кешеләр тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохитка, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясенең Музей фонды составына кертелгән музей әйберләренә һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясенең Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, аерым тарихи, фәнни, мәдәни билгеләнешкә ия булган, милли китапханәләр фондына керүче документларга, дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт һәм муниципаль мөлкәткә зарар китерүне булдырмау, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны кисәтү буенча чаралар, шулай ук федераль законнар белән каралган башка чараларны үткәрү турында күрсәтмә бирергә;

2) ачыкланган бозуларны бетерү, аларны кисәтү, кешеләр тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохитка, Россия

Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясенең Музей фонды составына кертелгән музей әйберләренә һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясенең Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, аерым тарихи, фәнни, мәдәни билгеләнешкә ия булган, милли китапханәләр фондына керүче документларга, дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт һәм муниципаль мөлкәткә зарар китерүне булдырмау, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны булдырмау, контрольлек итү буенча чаралар, шулай ук ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җавапка тарту буенча чаралар кабул итәргә.

2. Әгәр тикшерү үткәргән вакытта юридик зат, аның филиалы, вәкиллеге, структур подразделениесе, шәхси эшмәкәр эшчәнлеге, аларның зданиеләрне, корылмаларны, биналарны, җиһазларны, шундый объектларны, транспорт чараларыннан эксплуатацияләве, алар җитештергән һм сата торган товарларның (башкарган эшләре, күрсәткән хезмәтләре) турыдан-туры кешеләр тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохитка, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясенең Музей фонды составына кертелгән музей әйберләренә һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясенең Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, аерым тарихи, фәнни, мәдәни билгеләнешкә ия булган, милли китапханәләр фондына керүче документларга, дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт һәм муниципаль мөлкәткә зарар китерү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы тудырсалар яки шундый зарар ясалган булса, дәүләт контроле органы (күзәтчелек), муниципаль контроль органы тиз арада зарар китерүгә юл куймау яки аның зарар китерүен туктату буенча Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексы белән билгеләнгән тәртиптә юридик затның, аның филиалының, вәкиллегенең, структур подразделениесенең, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеген вакытлыча тыю, гражданнарның тормышы, сәламәтлеге өчен һәм әйләнә-тирә мохит өчен куркыныч тудыручы продукцияне әйләнештән алу һәм бу турыда гражданнарга җиткерү, шулай ук башка юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә хәбәр итү буенча мөмкин булган теләсә нинди ысул белән зарар китерү куркынычы булу һәм аны булдырмау ысуллары турында чаралар кабул итәргә тиешләр.

3. Белем бирү сыйфатына тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган чаралар 2012 елның 29 декабрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә мәгариф турында”гы 273нче Федераль закон белән билгеләнә.

3.9. Тикшерү үткәрелгән юридик зат, шәхси эшмәкәр тикшерү актында язылган фактлар, чыгарылмалар, тәкъдимнәр белән яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәләр белән килешмәсә, тикшерү актын алган көннән алып унбиш көн эчендә муниципаль контрольнең тиешле органына язма формада тикшерү актының һәм (яки) ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәнең тулаем яки аерым нигезләмәләренә карата дәгъва белдерергә хаклы. Шуның белән бергә юридик зат, шәхси эшмәкәр шундый дәгъваларга әлеге дәгъваларның нигезлеген раслаучы документлар яки аларның раслатылган күчермәләрен беркетергә яисә килешенгән срокта аларны муниципаль контроль органына тапшырырга хаклылар. Күрсәтелгән документлар тикшерелүче затның көчле квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документлар формасында (электрон документлар пакеты) җибәрелергә мөмкин.

**IV “Гариза бирүченең муниципаль контроль органының, муниципаль контроль органының вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе”**

5.1. Гариза бирүченең муниципаль контроль органының, муниципаль контроль органының вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерүгә хакы бар.

Гариза бирүче дәгъва белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) муниципаль контроль турындагы гаризаны теркәү срогын бозу;

2) күрсәтелгән очракта муниципаль контроль срогын бозу. Әлеге очракта гариза бирүченең күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирә ала, әгәр карараларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль контроль буенча функция йөкләнгән булса;

3) Гариза бирүчедән муниципаль контроль өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган документлар яки мәгълүматлар яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) Гариза бирүчедән муниципаль контроль өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-

хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар, әлеге Адмиnnистратив регламент белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) муниципаль контроль күрсәтүдән баш тарту, әгәр баш тарту сәбәпләре Россия Федерациясенең федераль законнары һәм алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять белдерүе мөмкин, әгәр күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль контрольне тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса.

6) гариза бирүчедән муниципаль контроль күрсәткәндә Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган түләүләр таләп итү;

7) Башкарма комитетның, башкарма комитетның вазифаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешманың яки аларның хезмәткәрләренең, дәүләт яки муниципаль контроль нәтиҗәсендә бирелгән документларда үзләре җибәргән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срокларын бозу. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең судка кадәрге (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүе мөмкин, әгәр шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль контрольне тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса;

8) муниципаль контроль күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогын һәм тәртибен бозу;

9) муниципаль контрольне туктату, әгәр туктату сәбәпләре Россия Федерациясенең федераль законнары һәм алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән карарлмаган булса. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең судка кадәрге (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүе мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль контролен тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса.

10) гариза бирүчедән дәүләт яки муниципаль контроль күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны (аларның булмаулары һәм (яки) дөрес булмаулары) таләп итү яисә 27.07.2010 елгы 210 нчы Федераль законның 7нче маддәсенең 1 өлешенең 4 нче бүлегендә каралган очраклардан кала, дәүләт яки муниципаль контроле. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең судка кадәрге (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүе мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль контрольне тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса.

5.2. Гариза бирүчеләр шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны алуга хокуклы.

5.3.Шикаять 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган муниципаль контроль органына, күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне оештыручы булып торучы дәүләт властеның ( җирле үзидарә органы) ачык-хокукый берәмлеге булган тиешле органына (алга таба – күпфункцияле үзәкне оештыручы), шулай ук 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешмаларга язмача формада кәгазьдә һәм электрон формада бирелә. Муниципаль органы орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять югарыгы органга ( әгәр ул булса) бирелә яисә ул булмаганда турыдан-туры муниципаль контроль органы җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять күпфункцияле үзәкне оештыручыга яисә Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары буенча вәкаләте булган вазифаи затка бирелә. 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы

номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә ( чара күрмәвенә) шикаять әлеге оешмалар җитәкчеләренә бирелә.

Муниципаль контроль органының, муниципаль контроль органының вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, муниципаль контроль органы җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәк, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайты, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәк, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайты, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешмалар, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәреннән файдаланып, әлеге оешмаларның рәсми сайтлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

. 5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) муниципаль контроль органы, муниципаль контроль органының вазифаи затының исеме яки карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән муниципаль хезмәткәрнең исеме;

2) гариза бирүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы әгәр булса), яшәү урыны турында белешмә, шулай ук элемтә өчен телефон номеры, электрон почта адресы ( әгәр булса) һәм почта адресы (адреслары), алар буенча гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиеш;

3) муниципаль контроль органының, муниципаль контроль органының вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү турында белешмә;

4) гариза бирүченең муниципаль контроль органының, муниципаль контроль органының вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмауларына) белән килешмәвен нигезләүче дәлилләр. Гариза бирүче үз дәлилләрен рслаучы документлар (алар булганда) яисә аларның күчермәләрен тәкъдим итә ала.

5.5. Әгәр шикаятьне карау өчен әһәмиятле нәрсәләр булган документлар булмаса яки алар шикаятькә беркетелмәгән булса, карар дәлилләрне ( аларны раслаучы документлар тәкъдим ителмәгән) исәпкә алмыйча гына кабул ителә.

5.6 Шикаять муниципаль контроль органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәк учредителенә, 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югарыгы органга (ул булганда) кергәндә, ул аны теркәгәннән соң унбиш эш көне дәвамында каралырга тиеш, әгәр муниципаль контроль органы, күпфункцияле үзәк, 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешма гариза бирүчедән доументларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуга шикаять белдерсә яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылу турындагы шикаять булса – аны теркәгәннән соң биш эш көне дәвамында.

5.7. Муниципаль контроль органы шикаятьләрне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, бирелгән муниципаль контроль нәтиҗәсе документларында җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү, гариза бирүчегә акча түләү Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, Чистай муниципаль районының муниципаль хокукый актлар белән каралмаган очракта акчаны кире кайтару формасында.

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарталар.

Карар кабул иткән көннән соң килә торган икенче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача формада һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында сәбәпләр күрсәтелән җавап җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылганда, гариза бирүчегә җавапта муниципаль контроль органы, күпфункцияле үзәк, 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешма башкарырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат

бирелә, бу муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган бозуларны тиз арада бетерү максатында эшләнә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм гариза бирүчегә муниципаль контроль алу максатында нәрсә эшләргә тиешлеге турында мәгълүмат бирелә.

Шикаятьне канәгатьләндерү мөмкин түгел дип табылганда, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында аргументлаштырылган аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки вазифаи затның, шикаятьне карау буенча вәкаләте булган хезмәткәрнең җинаять кылу билгеләре ачыкланса, булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына җибәрәләр

## IV. МУНИЦИПАЛЬ КОНТРОЛЬНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ ОРГАННЫҢ, ШУЛАЙ УК АНЫҢ ВАЗИФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ КАРАРЛАРЫНА ҺӘМ ГАМӘЛЛӘРЕНӘ (ГАМӘЛ КЫЛМАУЛАРЫНА) СУДКА КАДӘРГЕ (СУДТАН ТЫШ) ШИКАЯТЬ БЕЛДЕРҮ ТӘРТИБЕ

4.1.Юридик зат җитәкчесе, башка вазифаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, гражданнар, аларның вәкаләтле вәкилләре тикшерү үткәргәндә хакимиятнең вазифаи затларының юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, гражданнарның хокукларын бозуга китергән гамәлләренә ( гамәл кылмауларына) Россия Федерациясе законы нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерергә хаклы.

4.2. Юридик зат, шәхси эшмәкәр, гражданин тарафыннан муниципаль контроль органы вазифаи затларының гамәлләренә ( гамәл кылмауларына) шикаять кәгазьдә язма формада яисә электрон формада муниципаль торак контроль органына, муниципаль торак контроле органы җитәкчесенә бирелә;

4.2.1.Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

-язма мөрәҗәгать җибәрелә торган җирле үзидарә органы исеме яисә тиешле вазифаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме яисә тиешле затның вазифасы;

- гариза бирүче турында белешмә: гражданнар өчен - фамилиясе, исеме, атасының исеме ( соңгысы әгәр булса), юридик затлар өчен –вазифаи затның фамилиясе һәм инициаллары белән оешма исеме, җавап, мөрәҗәгатьне башка адреска җибәрү турында хәбәрне җибәрү өчен почта адресы;

- тәкъдимнең, гаризаның яки шикаятьнең асылын язарга;

- гариза бирүченең шәхси имзасы (юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен – гариза бланкта рәсмиләштерелә яисә гаризага штамп куела, ә имза мөһер белән ( әгәр булса) раслана) һәм кул кую көне.

Җирле үзидарә органына яки вазифаи затка электрон документ формасында кергән мөрәҗәгать 2006 елның 2 маенда кабул ителгән "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында"гы 59 нчы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш.Мөрәҗәгатьтә гражданин мәҗбүри тәртиптә үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен ( соңгысы әгәр булса), җавап, мөрәҗәгатьне башка адреска җибәрү турында хәбәрне җибәрү өчен электрон почта адресын күрсәтергә тиеш. Гражданин шундый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалны электрон формада беркетергә тиеш.

4.2.2. Тикшерелә торган зат шикаятькә анда язылганнарны раслаучы документлар күчермәсен беркетергә хаклы. Мондый очракта шикаятьтә аңа беркетелгән документлар исемлеге китерелә (почта аша җибәргәндә кертелгәннәргә опись ясала)

4.3.Шикаять аны теркәгәннән соң утыз көн эчендә карала.

4.4. Судка кадәрге (судтан тыш) шикаять белдерүнең нәтиҗәсе булып тора:

- шикаять бирүченең таләпләрен тулысынча яисә өлешчә канәгатьләндерү;
- шикаять бирүченең таләпләрен тулысынча яисә өлешчә канәгатьләндерүдән баш тарту.

Эчтәлегендә шикаятьне карау нәтиҗәләре булган язмача җавап гариза бирүчегә тапшыру турында белдерү белән почта аша җибәрелә яисә аның таләбе буенча кулына тапшырыла.

4.5.Вазифаи затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына), карарларына булган шикаять түбәндәге очракларда каралмый:

- әгәр язма мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгать җибәргән гражданинның фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән булса. Әгәр әлеге мөрәҗәгатьтә хокукка каршы гамәлләр әзерләнүе, кылынуы яки кылынган булуы турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында хәбәр булса, мөрәҗәгатьне аның компетентлылыгы нигезендә дәүләт органына җибәрергә кирәк;
-әгәр шикаятьтә вазифаи затка, шулай ук аның гаилә әгъзалары тормышына, сәламәтлегенә, мөлкәтенә куркыныч янау, начар яисә мыскыллау сүзләре булса , анда куелган сораулар асылы буенча аңа җавап бирелми, бу турыда гариза бирүчегә язма рәвештә хәбәр ителә;
-әгәр шикаятьнең тексты укырлык булмаса, шикаятькә җавап бирелми, бу турыда гариза бирүчегә язма рәвештә хәбәр ителә, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укырлык булса.

4.6.Тикшерелүче зат муниципаль контроль органының вазифаи заты, муниципаль хезмәткәрләренең әлеге административ регламентны үтәү барышында кабул иткән гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына

Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән тәртиптә судка шикаять бирергә хаклы.

## V. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ

5.1 Муниципаль контроль органы, аның вазифаи затлары тикшерү үткәргәндә функцияләрне, хезмәт вазифаларын тиешенчә башкармасалар, хокукка каршы гамәлләр кылсалар Россия Федерациясе законы нигезендә җавап тоталар.

Муниципаль контроль органы җитәкчесе:

-вазифаи затларның хезмәт бурычларын үтәүгә контрольне тормышка ашыра;

- вазифаи затларның үз хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәү очракларын исәпкә ала;

- тиешле хезмәт тикшеренүләре уздыра;

-шундый вазифаи затларга карата Россия Федерациясе законы нигезендә чаралар кабул итә.

Россия Федерациясе законын бозуда гаеплеләргә карата кабул ителгән чаралар турында шундый чараларны кабул иткәннән сон 10 көн эчендә муниципаль контроль органы хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә язма формада хәбәр итәргә тиеш.

5.2. Муниципаль контроль органының 26.12. 2008 елгы 294 нче Федераль закон һәм әлеге регламентның оешмага һәм тикшерү үткәрүгә булган таләпләрен тупас бозып үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре юридик затның, шәхси эшмәкәрнең мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозуына дәлил була алмый һәм юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, вазифаи затның гаризасы нигезендә суд тарафыннан гамәлдән чыгарылырга тиеш.

Тупас бозуларга түбәндә каралган таләпләрне бозу керә:

1). 26.12. 2008 елгы 294 нче Федераль законның 9нчы маддәсенең 2. 3 нче өлешләре (планлы тикшерүләр үткәрү өчен нигезләр булмау өлешендә), 12 нче өлеше `һәм 10 нчы маддәнең 16 нчы өлешендәге (тикшерү үткәрү турындагы белдерү срогын билгеләү өлешендә);

1.1) әлеге Федераль законның 2 нче маддәсенең 7 нче һәм 9 нчы пунктларындагы (билгеләнгән тәртиптә аккредитация узмаган юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм билгеләнгән тәртиптә аттестация узмаган гражданнарга контроль буенча чаралар үткәрүгә җәлеп итү өлешендә);

(23.06.2014 елгы 160 нчы Федераль законның 1.1 пункты редакциясендә)

2). 26.12. 2008 елгы 294 нче Федераль законның 10нчы маддәсенең 2 нче пунктының 2, 3 нче өлешләре (планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен сәбәпләрне санау өлешендә), 5 нче өлешендәге (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына карата планнан тыш күчмә тикшерүне прокуратура органнары белән килештерү өлешендә) ;

3) 26.12. 2008 елгы 294 нче Федераль законның 13 нче маддәсенең 2 нче өлешендәге (кече эшмәкәрлек субъектларына карата тикшерү үткәрүнең срокларын һәм вакытын бозу өлешендә);
4) 26.12. 2008 елгы 294 нче Федераль законның 14 нче маддәсенең 1 нче өлешендәге (дәүләт контроле (күзәтчелек) органы, муниципаль контроль органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) боерыгы яки карарыннан башка тикшерү үткәрү өлешендә);
5) 26.12. 2008 елгы 294 нче Федераль законның 15 нче маддәсенең 1, 1.1 һәм 1.2 нче пунктындагы, 3 нче пунктындагы ( тикшерү предметына карамый торган документларны таләп итү өлешендә), 6 нчы пунктындагы (тикшерү үткәрүнең билгеләнгән срокларын арттыру өлешендә);
6) 26.12. 2008 елгы 294 нче Федераль законның 16 нчы маддәсенең 4 нче өлешендәге (тикшерү актын тәкъдим итмәү өлешендә);
7) әлеге Федераль законның 9 нчы маддәсенең 3 нче өлешендәге (планлы тикшерү үткәрү өлешендә, планлы тикшерү үткәрүнең еллык планына кертелмәгән);
(27.12. 2009 елгы 365 нче Федераль законның 7нче пункты белән кертелгән)
8) әлеге Федераль законның 12 нче маддәсенең 6 нчы өлешендәге (юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр (аларга карата тикшерү үткәрелә) белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы экспертларга, эксперт оешмаларына тикшерү үткәрүдә катнашу өлешендә).
(27.12. 2009 елгы 365 нче Федераль законның 8нче пункты белән кертелгән, 02.12. 2013 елгы 337 нче Федераль закон редакциясендә).)

Чистай муниципаль районы
территориясендә муниципаль юл
контролен гамәлгә ашыруның
административ регламентына
1 нче кушымта
(типовой форма)

2007 елның 8 ноябрендә кабул ителгән " Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турындагы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында"гы 257нче Федераль законын бозуны бетерү турындагы _____ нче КҮРСӘТМӘ

"___" __________ 20_______ . _____________________

(төзү урыны)

2007 елның 8 ноябрендә кабул ителгән " Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турындагы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында"гы 257нче Федераль законы пункты нигезендә

КҮРСӘТМӘ БИРӘМ:

( күрсәтмә бирелә торган тикшерелә торган юридик затның тулы һәм кыскартылган исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

| тәртип номеры | Күрсәтмә эчтәлеге | Үтәү вакыты | Нигезе (норматив-хокукый актка сылтау) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | | | |
| 2. | | | |

Күрсәтмә бирелгән зат әлеге күрсәтмәнең пунктларын үтәү турындагы мәгълүматны Чистай муниципаль районының муниципаль контроль бүлегенә күрсәтмәнең тиешле пунктларын үтәү срогы чыкканнан соң 7 көннән дә соңга калмыйча мәгълүмат җибәрергә тиеш.

Вазифа
МУ имза расшифровкасы

Күрсәтмә алынды:

Вазифа
МУ имза расшифровкасы

Чистай муниципаль районы
территориясендә муниципаль юл
контролен гамәлгә ашыруның
административ регламентына
2 нче кушымта
(типовой форма)

(муниципаль контроль органы исеме)

__________________________"___"___________20__ел.

(акт төзү урыны)

_________________

(актны төзү вакыты )

Муниципаль контроль органы тарафыннан физик затны ТИКШЕРҮ АКТЫ N _________

Адрес/адреслар буенча: ___________________________________________________

(тикшерү үткәрү урыны)

Нигезендә: _________________________________________________________

(реквизитлар күрсәтелгән документ төре (номеры, көне))

тикшерү үткшрелде ____________________________________________________

(планлы/планнан тыш, документлар буенча/күчмә)

тикшерү_______________________________________________________________карата

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Тикшерү үткәрү көне һәм вакыты:

"___"_________ 20__ ел. ___ сәгать ___ минуттан ___ сәгать ___ минутка кадәр.

Таныштым:
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Тикшерү үткәрү турындагы боерык күчермәсе белән таныштым (күчмә тикшерү үткәргәндә тутырыла):
(фамилияләр, инициаллар, имза көне, вакыты )

Тикшерү үткәрүне килештерү турында прокурор (аның урынбасары) карарының көне һәм номеры:

(тикшерүне прокуратура органнары белән килештерү зарурлыгы булганда тутырыла)

Тикшерүне үткәргән зат(лар):
(Тикшерү үткәргән вазифаи затның (вазифаи затларның) вазифасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы әгәр булса); тикшерүгә катнашуга экспертларны, эксперт оешмаларын җәлеп иткәндә фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы әгәр булса), аккредитацияләү турындагы таныклык реквизитларын һәм аккредитация буенча таныклык биргән органның исемен күрсәтеп, экспертларның вазифалары һәм/яки эксперт оешмасы исеме күрсәтелә)

Тикшерүне үткәргәндә катнаштылар:

(тикшерү буенча чаралар үткәргәндә катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Тикшерү үткәрү барышында:

мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозулар ачыкланды (бозуга юл куйган затларның хокукый (норматив) актлар нигезләмәләрен күрсәтеп):

(бозулар характерларын күрсәтеп)
дәүләт контроле (күзәтчелек) органнарының, муниципаль контроль органнарының күрсәтмәләрен үтәмәү фактлары ачыкланды (бирелгән күрсәтмәләрнең реквизитларын күрсәтеп):

бозулар ачыкланмады

____________________ _____________________

(тикшерүченең имзасы ) (тикшерелүченең имзасы)

Актка беркетелгән документлар::

______________________________________________________________

Тикшерү үткәргән затларның имзалары:

________________________________________

________________________________________

Тикшерү акты белән таныштым, барлык нигезләмәләр белән актлар күчермәләрен алдәым:

( тикшерелүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

"___"__________ 20__ ел.

_______________
(имза)

Тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында тамга:

(тикшерү үткәргән вәкаләтле вазифаи затның (затларның) имзасы)

Чистай муниципаль районы
территориясендә муниципаль юл
контролен гамәлгә ашыруның
административ регламентына
3 нче кушымта
(типовой форма)

Дәүләт контроле (күзәтчелек) органнарының, муниципаль контроль органнарының юридик затны, шәхси эшмәкәрне тикшерү (планлы/ планнан тыш, документлар буенча/ күчмә) тикшерү турындагы _________________ "__" ______________ ел. нче _____ БОЕРЫГЫ (Карары)

1. __________________________________________карата тикшерү үткәрергә

(юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы әгәр булса)

2. Урнашкан урыны: ______________________________________________________

(юридик затлар (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур подразделениеләре) яки шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны һәм эшчәнлеген фактта башкару урыны)

3.Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле затны(ларны) билгеләргә: _______

( тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазифаи затның (вазифаи затларның) вазифасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы әгәр булса)

4.Тикшерү үткәрүгә экспертлар сыйфатында эксперт оешмалары вәкилләреннән түбәндәге затларны җәлеп итәргә:_________________________________________________________________

(тикшерү үткәрүгә җәлеп ителүче экспертларның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы әгәр булса), һәм (яки) эксперт оешмасының исеме аккредитацияләү турындагы таныклык реквизитларын һәм аккредитация буенча таныклык биргән органның исемен күрсәтеп)

5. Билгеләргә:

әлеге тикшерү түбәндәге максат белән үткәрелә: ______________________________

Үткәрелә торган тикшерү билгеләгәндә түбәндәге мәгълүмат күрсәтелә:
а) планлы тикшерү үткәргән очракта:

- планлы тикшерү үткәрүнең расланган еллык планына сылтау;
б)планнан тыш күчмә тикшерү үткәргән очракта:
- ачылган бозуларны бетерү бетерү турында тикшерелүче затка элек бирелгән күрсәтмәнең реквизитлары, аларны үтәү срогы чыккан;
- гражданнарның, юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең дәүләт контроле (күзәтчелек) органына, муниципаль контроль органына кергән мөрәҗәгатьләренең һәм гаризаларының реквизитлары;
- Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте кушуы нигезендә бирелгән дәүләт контроле (күзәтчелек) органы боерыгының (әмеренең), реквизитлары;
- законнарны үтәүгә күзәтчелек кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләбе реквизитлары һәм таләпкә беркетелгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр реквизитлары
в) планнан тыш күчмә тикшерү үткәргән очракта, аны прокуратура органнары тарафыннан килештерергә кирәк, әмма кичектергесез чаралар кабул итү максатында тиз арада үткәрелергә тиеш, зарар китерү яисә тикшерелә торган таләпләрне бозу сәбәпле, әгәр

шундый зарар китерү яисә тикшерелә торган таләпләрне бозу турыдан-туры аны тәмамлау вакытына ачылган булса:

- бозуны ачыклаган вазифаи зат тарафыннан бирелгән тәкъдим ителгән документлар күчермәләре реквизитлары (рапорт, доклад язмасы һәм башкалар);

әлеге тикшерү бурычлары булып торалар: ______________________________

6. Әлеге тикшерү предметы булып тора ( кирәклесен билгеләргә):
мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар
белән билгеләнгән таләпләрне үтәү;
эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләре тормышка
ашыра башлау турында белдерүдә күрсәтелгән белешмәләрнең
мәҗбүри таләпләргә тәңгәл килүе;
дәүләт контроле (күзәтчелек) органы, муниципаль контроль
органы күрсәтмәүләрен үтәү;

чаралар үткәрү:
гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян китерүне, хайваннарга,
үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохитка зарар китерүне булдырмау;
табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп
чыгуны кисәтү буенча;
дәүләт иминлеген тәэмин итү буенча;
шундый зарар китерү нәтиҗәләрен бетерү буенча.

7. Тикшерү үткәрү срогы: __________________________________________

Тикшерү үткәрергә керешергә

"__" ____________ 20__ ел.

Тикшерүне тәмамларга

"__" ____________ 20__ елдан соңрак түгел

8. Тикшерү үткәрүнең хокукый нигезләре: _____________________________

(норматив-хокукый акт нигезләмәсенә сылтау, тикшерү шуның нигезендә гамәлгә ашырыла; тикшерү предметы булып торучы таләпләрне билгеләүче (норматив) хокукый актлар нигезләмәләренә сылтау)

9. Тикшерү процессында контроль буенча түбәндәге чараларны үткәрергә, тикшерү үткәрү максатына һәм бурычларына ирешү өчен кирәк: ____________

10. Дәүләт контролен (күзәтчелек) гамәлгә ашыру, муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча (алар булганда) административ регламентлар исемлеге (исемнәрен, номерларын һәм аларны кабул итү көннәрен күрсәтеп) :

11. Тикшерү үткәрү максатына һәм бурычларына ирешү өчен кирәк булган юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан бирелгән документлар исемлеге:___________________________

__________________________________________________

__________________________________________________

(тикшерү үткәрү турында боерык яки карар биргән
дәүләт контроле (күзәтчелек) органы, муниципаль
контроль органы җитәкчесенең, җитәкче урынбасарының
вазифасы, фамилиясе, инициаллары)

______________________________________________

(мөһер белән расланган имза)

(турыдан-туры боерык (карар) проектын әзерләгән вазифаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы әгәр булса) һәм вазифасы, элемтә өчен телефон, электрон адрес (әгәр булса)

Чистай муниципаль районы
территориясендә муниципаль юл
контролен гамәлгә ашыруның
административ регламентына
4 нче кушымта
(типовой
форма)

Вазифаи затның тикшерелүче затның территориясенә (бинасына) керүенә комачаулау турында АКТ

Тикшерү үткәргәндә: _______________________________________________,

( тикшерелүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (әгәр булса), яшәү урыны буенча адресы күрсәтелә)
"____" ________ 20__ ел. _____нче боерык нигезендә тикшерү үткәрү хокукына вәкаләте булган, муниципаль контрольне тормышка ашыручы зат тарафыннан (тикшерү үткәрүче вазифаи затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, алар биләгән вазифа) Чистай муниципаль районы территориясендә муниципаль юл контролен тормышка ашырганда гражданнарга тикшерү үткәрү буенча административ регламент белән билгеләнгән тикшерү үткәрү турында хәбәр ителгән тәртиптә,__________________ адресы буенча урнашкан тикшерелә торган территориягә (бинага) кергәндә каршылыклар булды (өстәмә мәгълүмат күрсәтелә)

Тикшерү үткәрүче вазифаи затлар:

___________________________________ _______________

( вазифаи затның Ф.И.О. ) (имза, дата)

___________________________________ _______________

вазифаи затның Ф.И.О. ) (имза, дата)
Гражданинның (вәкаләтле (имза, дата) вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (әгәр булса) __________________________________________

Чистай муниципаль районы
территориясендә муниципаль юл
контролен гамәлгә ашыруның
административ регламентына
5нче кушымта

(типовой форма)

яшәү урыны буенча адрес

**Документлар (мәгълүмат) тапшыру турында сорау**

__________________________________________________________________________сәбәпле,

(сорауның төп юнәлешләре күрсәтелә: мөрәҗәгать керү, күрсәтмәне
үтәү срогы чыккан, боерык нигезендә мәҗбүри
таләпләрне бозу билгеләре турында сөйләүче материаллар
ачылган ( муниципаль контроль органы исемен күрсәтергә)

"___" _________ 20__ ел. N ____

тикшерү үткәрү турында _________________________________________________

______________________________________________-

__________________________________

(Тикшерелүче затның Ф.И.О.)

тапшырылырга тиеш:

1. ____________________________________

2. ____________________________________

3. ____________________________________

(соралган документлар санала, мәгълүмат)

Тапшыру срогы ____________ 20__ елдан соңрак түгел.

Тикшерелүче затның тикшерү үткәргәндә соралган документларны һәм мәгълүматларны тәкъдим итүдән баш тартуы яки аларны билгеләнгән срокта бирмәве өчен Россия Федерациясе законы нигезендә җаваплылык каралган.

Кушымта: тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсе

Муниципаль контроль органы
җитәкчесе (җитәкче урынбасары) _________________________________________________

Вазифаи затлар ____________________________________________________.

Әлеге сорауны алды __________ 20__ ел.

Ф.И.О. _________________________________________/_____________ (имза)

(Тикшерелүче затның, аның вәкаләтле вәкиленең (ышаныч язуының номерын һәм көнен күрсәтү мәҗбүри) фамилиясе, исеме, атасының исеме)